ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.07.2022 ел Баулы шәһәре №158

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 228 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында халыкны транспорт белән тәэмин итүгә бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 228 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында халыкны транспорт белән тәэмин итүгә бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирүче вәкаләтле орган һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләрне гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турында килешү»;

4.2. пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче һәм өченче абзац өстәргә:

«Субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү турында килешү имзалану һәм аны

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты адресына җибәрү өчен вакыт - 2 календарь көн.

Бирелә торган субсидияләр турында мәгълүмат Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгының Бердәм порталында, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан муниципаль финанс органнары өчен техник мөмкинлекне гамәлгә ашырганнан соң урнаштырылырга тиеш.»;

4.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге субсидияләрне үз шәхси счетларыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Баулы муниципаль районы буенча Казначылык департаментының Территориаль бүлегендә ачылган шәхси счетларыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениеләрендә субсидияләр алучы тарафыннан исәп-хисап яисә корреспондент счетына күчерә.

Әлеге Тәртипнең 4.2. пунктында билгеләнгән срокларда килешү төзелгән очракта, субсидия алучыга субсидия бирү срогы: Комиссия тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән вакыттан алып унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча, әмма бу елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.8. пункт өстәргә:

«4.8. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе - Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау.»;

6.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактларын ачыклау турында Башкарма комитеттан тиешле таләп алынган көннән, бирелгән субсидияләр Баулы муниципаль районы бюджеты кеременә 30 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.»;

7.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органы субсидия алучылар тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлүен, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерәләр.»;

түбәндәге эчтәлекле 7.3. пункт өстәргә:

«7.3. Башкарма комитет тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләренең казанышларына ирешү мониторингы килешүләрдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидияләр (контроль нокта) бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләр буенча мониторинг уздырыла.».

2. Әлеге карарның 7.3 пункты 2023 елның 1 гыйнварыннан кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров